МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ
И ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

25.09.2024

**БОЕРЫК**

№ 563-пр

Казан ш.

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы аларга мөнәсәбәтле гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә кайбер максатлар өчен бирелүче Татарстан Республикасы бюджеты акчасы финанс чыганагы булып торган субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78[1] статьясының 1 пунктының икенче абзацы, “Дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә кайбер максатлар өчен субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибен көйләүче норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында” Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 22 февралендәге № 203 карары, Дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә кайбер максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын һәм аның күләмен билгеләү тәртибен көйләү вәкаләтләре булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында, һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларын көчен югалткан дип тану турында” Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 28.02.2022 № 178 карары нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

аларга мөнәсәбәтле гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә кайбер максатлар өчен бирелүче Татарстан Республикасы бюджеты акчасы финанс чыганагы булып торган субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләүнең тәкъдим ителгән Тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы аларга мөнәсәбәтле гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә кайбер максатлар өчен бирелүче Татарстан Республикасы бюджеты акчасы финанс чыганагы булып торган субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау турында» 23.11.2022 № 675-пр боерыгын көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге боерык 2025 елның 1 гыйнварыннан үч көченә керә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Министр А.Р.Кадыйров

Татарстан Республикасы Җир һәм
мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
25.09.2024 № 563-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы аларга мөнәсәбәтле гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә кайбер максатлар өчен бирелүче Татарстан Республикасы бюджеты акчасы финанс чыганагы булып торган субсидияләр күләмен һәм бирү шартларын билгеләү Тәртибе

I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) аларга мөнәсәбәтле гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен тормышка ашырган дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә (алга таба – учреждение) кайбер максатлар өчен бирелүче Татарстан Республикасы бюджеты акчасы финанс чыганагы булып торган субсидияләр (алга таба – Тәртип, субсидия) күләмен һәм бирү шартларын, Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^{1}$ статьясы 1пунктның икенче абзацы нигезендә билгели.

Субсидия түбәндәге учреждениеләргә бирелә:

«Республика мөлкәт казнасы» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Матди тәэминат идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Дәүләт кадастр бәяләве үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Татарстан Республикасы пространство белешмәләре фонды » дәүләт бюджет учреждениесе.

2. Учреждениегә субсидия бирү максаты булып түбәндәгеләр тора:

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән эш итү” дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында планланган вакыт эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслаган чараларны үткәрү буенча учреждение эшчәнлеген тәэмин итү;

учреждение хезмәткәрләренә түләүләр;

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне карап тоту чыгымнары дәүләт хезмәте күрсәтүнең (эш башкару) норматив чыгымнарына кертелмәгән очракта аларны карап тоту буенча чаралар күрү;

мөлкәт алу.

II бүлек. Субсидия бирү шартлары һәм тәртибе

3. Субсидия алу өчен учреждение Татарстан Республикасы бюджетының акча чаралары белән төп эш итүче һәм алучы вәкаләтләрен башкаручы һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарына туры китереп, бюджет чараларын алучы буларак тиешле финанс елына бюджет йөкләмәләре лимиты тиешле тәртиптә җиткерелгән Министрлыкка субсидия бирү максатыннан чыгып түбәндәгеләрне тапшыра:

әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга субсидия бирү ихтыяҗын нигезләгән, субсидия суммасының бәясе нигезләве кертелгән аңлатма язуы, субсидия суммасының хисабы-нигезләвен дә кертеп;

тиешле эшләрне башкаруның (хезмәт күрсәтү), чаралар үткәрү, мөлкәт сатып алу (күчемсез милектән башкасын) якынча сметасы, шулай ук, хезмәт куя алучыларның (подрядчиклар, башкаручылар) тәкъдимнәре, статистик һәм (яки) башка мәгълүмат;

субсидия бирелү максаты ремонт ясау (реставрация) булган очракта, ремонт соралган объектлар исемлеге, андый объектларны тикшерү акты һәм дефект ведомосте, чыгымнарның якынча сметасы;

субсидия бирелү максаты чаралар, шул исәптән, конференцияләр, симпозиумнар, күргәзмәләр үткәрү булса, чараларның программасы;

субсидия бирелү максаты мөлкәт алу булган очракта, алынырга планлаштырылган мөлкәт турында мәгълүмат;

субсидия бирелү максаты күрәстелгән түләүләр булган очракта, түләүләрне алучы физик затлар саны (еллык уртача сан) һәм түләүләр төре турында мәгълүмат;

субсидия бирелү максатыннан чыгып башка мәгълүмат.

4. Документлар кергән көнендә регистрацияләнә. Министрлык әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгәнчә, документлар алынгач биш эш көне эчендә кабул ителгән документларны карый һәм субсидия бирү яки бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

5. Субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

бирелгән документларның әлеге Тәртипнең 3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, яки күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

учреждение тапшырган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы.

6. Субсидия күләме учреждение тапшырган документлардан чыгып, туры килгән финанс елына һәм пландагы вакытка Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законнарында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә билгеләнә, субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән билгеләнгән очраклар чыгарылма булып тора.

7. Субсидия бирү турында карар кабул ителгәч, биш эш көне эчендә Министрлык һәм учреждение Татарстан Республикасының дәүләт бюджет яки автоном учреждениесенә Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясенең Бюджет кодексының 78[1] статьясы 1 пунктының икенче абзацына туры китереп, Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгының 22.12.2016 № 17-148 боерыгы белән расланган типовой формада (алга таба – Килешүнең типовой фоомасы) субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзиләр, анда түбәндәге кагыйдәләр була:

субсидия бирелү максаты;

субсидия бирелү нәтиҗәсенең әһәмияте;

субсидия бирелү нәтиҗәсенә ирешү өчен кирәкле күрсәткечләр;

субсидия бирелү нәтиҗәсенә ирешү буенча чаралар планы;

субсидия күләме;

субсидия күчерү сроклары (графигы);

отчет бирү сроклары;

учреждение килешүдә билгеләнгән субсидия бирелү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта субсидия суммасын кайтару тәртибе һәм сроклары;

килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Министрлыкка субсидия бирү өчен алдан җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитының кимetelүе очрагын да кертеп;

Министрлык карары белән килешүне алдан берьяклы туктату өчен нигезләр, шул исәптән, түбәндәге сәбәпләргә бәйле:

- учреждениене үзгәртү (кушу формасынданы үзгшртү чыгарылма булып тора) яки бетерү;

- учреждениенең әлеге Тәртип һәм (яки) килешү белән билгеләнгән субсидия бирелү максатларын һәм шартларын бозуы;

учреждениенең килешүне берьяклы тәртиптә өзүен тыю.

Ихтыяҗ булган очракта Министрлык һәм учреждение килешүнең типовой формасына 6 нчы һәм 7 нче кушымталардагы формалар буенча килешүгә өстәмә килешү яки килешүне өзү турында өстәмә килешү төзиләр.

8. Килешү төзү планлаштырылган ай алдыннан килгән айның беренче көнендә учреждениенең Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары буенча түләнергә тиешле булып түләнмәгән салымнары, җыемнары, страховка взнослары, пенялары, штрафлары, процентлары, Татарстан Республикасы бюджетына хокукый актлар нигезендә субсидияләр, бюджет инвестицияләрен кайтару буенча тиешле вакытында түләнмәгән бурычлары булмау учреждение туры килгән таләп булып тора.

9. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып субсидия бирү максатына туры килгән һәм

субсидия хисабына башкарылырга планлаштырылган чараларның гомуми өлешчә фактта үтәлүе тора (100 проценттан да ким түгел), шул исәптән бирү максатыннан чыгып:

субсидия әлеге Тәртипнең 2 пунктының икенче, дүртенче абзацларына туры китереп чаралар үткәрергә бирелгән очракта үткәрелгән чаралар саны (бер чарадан да ким түгел);

түләүләр алучыларга түләү өчен субсидия бирелү хисабына кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмдә);

субсидия мөлкәт алу өчен бирелгән очракта алынган милек объектлары саны (милек объекты берддән дә ким түгел).

Субсидия бирү нәтиҗәләренең ирешү срогы – субсидия бирелгән елның 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

10. Министрлык субсидияне, килешү шартларына туры китереп, учреждениенең Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган лицевой счетына күчерә.

## III бүлек. Отчетка таләпләр

11. Учреждениеләр Министрлыкка ел саен, отчет периодыннан соң килгән айның 10 нчы көненнән дә соңга калмыйча түбәндәгеләрне тапшыралар:

килешүнең типовой формасының 4 нче кушымтасы формасы буенча финанс чыганагы субсидия булган чыгымнар турында отчет;

килешүдә билгеләнгән форма буенча чаралар планы үтәлүе турында отчет;

килешүнең типовой формасының 5 нче кушымтасы формасы буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында отчет.

12. Гамәлгә куючы килешүдә өстәмә отчет формалары һәм срокларын билгеләргә хокуклы.

## IV бүлек. Бирелгән субсидиянең максатлары, шартлары һәм тәртибе саклануын контрольдә тоту һәм бозылган очракта җаваплылык тәртибе

13. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы бирелгән субсидиянең максатлары һәм шартлары саклануын мәҗбүри тикшерә.

Субсидия бирүнең килешүдә күрсәтелгән нәтиҗәләренә ирешүне һәм субсидия бирелү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар тәмамлану фактын чагылдыручы вакыйгалар мониторингы Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Финанслар Министрлыгы билгеләгән тәртиптә үткәрелә.

14. Учреждение субсидия алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар биргән өчен, субсидия бирүнең шартларын һәм тәртибен бозган өчен,

шулай ук, субсидияне тоту максатлары, әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән отчетларны бирмәгән өчен җавап тота.

15. Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары үткәргән тикшеренүләр нәтиҗәсендә учреждениенең субсидия бирелгәндә билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәгәнлеге ачыкланган очракта, субсидия бирүнең әлеге Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән нәтиҗәләренә ирешелмәгәндә, Министрлыкның тиешле таләбен алганнан соң учреждение тарафыннан субсидия 30 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

16. Учреждение әлеге Тәртипнең 15 пунктында билгеләнгән 30 көн эчендә субсидия акчалары кайтарылырга тиешле срокны бозса, Министрлык субсидия акчаларын Татарстан Республикасы бюджетына кайтару өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чараларны күрә.

17. Субсидия чараларының отчеттагы финанс елында файдаланылмый калганын отчет елыннан соң килгән елның 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кайтарыла, Министрлыкның субсидия чараларының агымдагы финанс елында кулланылмаган өлешен әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлтү ихтыяҗы турында карары искәрмә булып тора.

18. Субсидия чараларының агымдагы финанс елында кулланылмаган өлешен әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлтү ихтыяҗы булган очракта учреждение отчет елыннан соң килгән елның 15 гыйнварыннан да соңга калмыйча Министрлыкка үтәлми калган йөкләмәләр булуы турында мәгълүмат юллый, аларның финанс тәэминаты чыганагы булып агымдагы елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидия өлеше тора, шулай ук, учреждениенең күрсәтелгән йөкләмәләренең булуы һәм күләмен (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләр искәрмә булып тора) раслаган документлар (документларның күчермәсе).

19. Министрлык учреждениедән 18 нче пункта күрсәтелгән мәгълүматны алганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча файдаланылмаган субсидия өлешен әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлтү ихтыяҗы булуы яки булмавы турында карар кабул итә.

20. Министрлык файдаланылмаган субсидия өлешен әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен юнәлтү ихтыяҗы булуы турында карар кабул иткән очракта Министрлык белән учреждение арасында карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә килешүгә өстәмә килешү төзелә.

21. Агымдагы финанс елында финанс чыганагы субсидия булган учреждение тарафыннан кире кайтарылган түләүләр булса, Министрлык учреждениенең үтәлмәгән һәм финанс чыганагы учреждение алдарак кайтарган түләүләр булган йөкләмәләре булуы турында мөрәҗәгате, шулай ук, учреждениенең курсштелгән

йөкләмәләре булуы һәм аларның күләмен (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләр искәрмә булып тора) раслаган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә аларны әлеге Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга ирешү өчен учреждение тарафыннан кулланылу турында учреждение мөрәҗәгатен алганнан срд биш көн эчендә карар кабул итә.